СОВЕТ КАТМЫШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Кирова, д.74, с. Катмыш,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422177

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАТМЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Киров ур., 74 нче йорт, Катмыш авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422177

тел.(факс): (85563) 4-05-21; e-mail: Katmish.Mam@tatar.ru, www:mamaduYsh.tatarstan.ru

Решение — Карар

№3-23 — 28 март 2023 ел

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге Советының керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы Конституциясенәүзгәрешләркертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы таләпләренә туры китерү максатында, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Катмыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Катмыш авыл җирлеге Советының 2022 елның 15 августындагы 2-17 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге советы депутаты статусы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нче кушымтаның 3 статьясының 3 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 1 нче кушымтаның 18 статьясының 1пунктындагы “б” пунктчасында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

2. Катмыш авыл җирлеге Советының 2016елның 03 мартындагы 1-7 номерлы карары беләнрасланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. 1 нче кушымтаның 11.9. пунктында«Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренәалмаштырырга;».

3. Катмыш авыл җирлеге Советының 2020 елның 22 июнендәге 2-54 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына карата үзкеремнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының

керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүмат биргән өчен, әгәрдә бу мәгълүматларны бозып бирү артык зур булмаса, җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1. Кушымтаның 3 пунктының 2абзацында, 4 пунктта, 5 пунктның 2 абзацында, 6 пунктның 1 абзацында, 7 пунктның 1 һәм 3 абзацларында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

3.2. Кушымтаның 11 пунктынның 1 абзацында «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;».

4. Әлеге карарны авыл җирлегененңмәгълүматистендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсмисайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы беләнигъланитәргә.

5. Әлеге караның үтәлешен контрольдә тотуныТатарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Катмыш
авыл җирлеге башлыгы,
авыл җирлеге Советы рәисе И.Г.Габидуллин